ГЛАВА АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.02.2021 п.г.т. Алексеевское № 6

**2021 елда Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын үткәрү эшен оештыру турында**

Татарстан Республикасы Президентының «2021 елны Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халык бердәмлеге елы дип игълан итү турында» 2020 елның 5 октябрендәге ПУ-653 номерлы Указын, «2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча Республика оештыру комитеты төзү турында» Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 15 декабрендәге ПУ-841 номерлы Указын үтәү йөзеннән

**карар бирәм**:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә (алга таба - оештыру комитеты).

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- оештыру комитеты турында нигезләмә (1 нче кушымта).
- оештыру комитеты составы (2 нче кушымта).
- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын 2021 елда уздыру буенча төп чараларның муниципаль планы (3 нче кушымта).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе О.А. Гайнуллинга йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А. Демидов**

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы башлыгының
2021 елның 4 февралендәге
6 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2021 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында Нигезләмә**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы карары белән төзелгән.

2. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:
- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын 2021 елда уздыру буенча төп чараларның муниципаль план чараларын әзерләүгә һәм уздыруга бәйле тәкъдимнәрне карау һәм гомумиләштерү;
- Планның төп чараларын гамәлгә ашыруны оештыру һәм тикшереп тору.

3. Үз бурычларын үтәү өчен оештыру комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:
- төп чараларны гамәлгә ашыру турындагы проектларны һәм тәкъдимнәрне карарга, Планның төп чараларын финанслауның бюджеттан тыш чыганакларын җәлеп итүгә ярдәм итәргә;
- үз утырышларында Планның төп чараларын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләр буенча оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләрен тыңларга;
- чараларда катнашучыларны һәм җаваплы затларны билгеләргә.

4. Оештыру комитеты утырышлары кирәк саен үткәрелә, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Утырышларны комитет рәисе яки аның урынбасары үткәрә. Оештыру комитеты утырышларының көн тәртибен, аны үткәрү урынын һәм тәртибен оештыру комитеты рәисе йә, ул булмаганда, аның урынбасары билгели.

5. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала. Оештыру комитеты карарлары оештыру комитеты утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Оештыру комитеты әгъзасы утырышта булмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы. Әлеге документ оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә кушып бирелә.

6. Оештыру комитеты кабул иткән карарлар рекомендация характерында була, кызыксынучы затларга беркетмәдән өземтә рәвешендә җиткерелә.

7. Комитетның карарларына законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

**Совет аппараты җитәкчесе** **А.С. Харитонов**

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы башлыгының
2021 елның 4 февралендәге
6 номерлы карарына
2 нче кушымта

**2021 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Демидов Сергей Анатольевич | Алексеевск районы башлыгы, рәис |
| Гайнуллин Олег Александрович | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, рәис урынбасары |
| Мөбарәкшин Булат Нургаян улы | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ милли белем бирү методисты, сәркатип |
| Әгъзалар: | |
| Симашева Альбина Валентиновна | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары - «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| Свистунова Алёна Михайловна | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының район мәдәният йорты» МБУ директоры |
| Кладова Ольга Германовна | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының В.И. Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ директоры |
| Бурмакина Ольга Анатольевна | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУ директоры |
| Салюков Евгений Григорьевич | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма |

| | |
|---|---|
| | комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы |
| Козонкова Лариса Геннадьевна | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы |
| Хәмзина Елена Александровна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Гатина Рәфидә Мәүлетшәриф кызы | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы Халыклар ассамблеясе вәкиллеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Монина Ирина Юрьевна | «Татмедиа» ААҖ филиалы директоры - Алексеевск районы «Заря» («Таң») газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Макарихина Елена Степановна | Алексеевск муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Чурашов Павел (Михайлович) | Алексеевск благочиниесе благочинные, Изге Алексия мәхәлләсе настоятеле (килешү буенча) |
| Вальщиков Рөстәм Нәбиулла улы | Алексеевск муниципаль районы имам-мөхтәсибе (килешү буенча) |

**Совет аппараты җитәкчесе** **А.С.Харитонов**

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы башлыгының
2021 елның 4 февралендәге
6 номерлы карарына
3 нче кушымта

**2021 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын уздыру буенча төп чараларның муниципаль планы**

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Халыкара туган тел көненә багышланган айлык, шул исәптән:<br>- Татарстан Республикасында яшәүче халыклар катнашында концерт программалары;<br>- Халыкара туган тел көненә багышланган тематик программалар | 20 нче гыйнвар – 21 нче февраль | Төп эшчәнлек кысаларында | МУ, РМБ, ЯЭСБ* «Татмедиа» филиалы («Таң» газетасы («Заря»). |
| 2. | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын тантаналы ачу | 5 нче февраль | Төп эшчәнлек кысаларында | МУ, РМБ, ЯЭСБ |
| 3. | Социаль челтәрләрдә «Туган телдә сөйләшәбез һәм укыйбыз» промоакциясе | февраль | «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында | РМБ, МУ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | | | башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» ТР ДП* кысаларында | |
| 4. | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ Советының «Алексеевск мниципаль районында милли мәгарифне үстерү: проблемалар һәм чишү юллары» темасына киңәйтелгән утырышы | Февраль | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |
| 5. | Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләрен иң яхшы яктырту буенча республика журналистлар конкурсында катнашу | февраль – сентябрь | «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | «Татмедиа» филиалы («Таң» газетасы («Заря») |
| 6. | «Күпкырлы Россия» Бөтенроссия журналистлар конкурсында катнашу | февраль – октябрь | «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | «Татмедиа» филиалы («Таң» газетасы («Заря») |
| 7. | «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» Бөтенроссия фотоконкурсында катнашу | февраль – ноябрь | «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәтен | РМБ, МУ, «Татмедиа» филиалы («Таң» газетасы («Заря») |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | | | гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | |
| 8. | Польша композиторы һәм пианисты Фредерик Шопенның тууына 211 ел тулуга багышланган балалар музыка фестиваль-конкурсында катнашу | 1 нче март | Төп эшчәнлек кысаларында | «АБСМ» ӨББ МБО * |
| 9. | «Музей масленицасы» этнографиясе буенча кече мәктәп укучылары өчен комплекслы музей чарасы | 8-12 нче март 2021 ел | Төп эшчәнлек кысаларында | «В.И. Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ |
| 10. | «Май чабу» славян мәдәнияте бәйрәмен үткәрү | март | «2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | МУ, РМБ |
| 11. | «Нәүрүз» төрки халыклар бәйрәмен үткәрү | март | «2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | «РМЙ» МБУ<br>ТР Халыклар ассамблеясенең АМР вәкиллеге |
| 12. | «Туган телләр укытучыларының мастер-классы» Бөтенроссия конкурсының муниципаль этабын оештыру һәм үткәрү | март | «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм | РМБ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | | | Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» ТР ДП кысаларында | |
| 13. | Авыл мәдәният йорты һәм авыл клубларының «Туган тел – саекмас чишмә»/«Родной язык – неиссякаемый родник» иҗат коллективлары арасында район смотр-конкурсы | март | Төп эшчәнлек кысаларында | «РМЙ» МБУ |
| 14. | «Туган як тарихында хатын-кызның роле» экскурсия элементы белән тематик фонд күрсәтмәсе | Март, ноябрь 2021 (гаризалар буенча мәгълүмат) | Төп эшчәнлек кысаларында | «В.И. Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ |
| 15. | Туган тел көненә һәм бөек татар шагыйре Г. Тукайның тууына 135 ел тулуга багышланган чаралар үткәрү (мәдәният, мәгариф оешмалары, яшьләр сәясәте учреждениеләренең аерым планнары буенча) | 26 нчы апрель | «2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | МУ, РМБ, ЯЭСБ |
| 16. | Бөек татар шагыйре Г. Тукайның тууына 135 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашу | апрель | финанслау чыганагы билгеләнмәгән | РМБ |
| 17. | Габдулла Тукай исемендәге Халыкара шигырь укучылар конкурсының муниципаль этабын | апрель | финанслау чыганагы билгеләнмәгән | МУ, РМБ, ЯЭСБ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | оештыру һәм үткәрү | | | |
| 18. | Туган тел Декадаларын оештыру һәм үткәрү, шул исәптән:<br>- Татар теле буенча халыкара олимпиада;<br>- «Татар теленең виртуаль кабинеты» конкурсы | апрель | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |
| 19. | Яшь шагыйрьләр, язучылар һәм драматургларның «Илһам» Бөтенроссия фестивалендә катнашу | апрель | «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» ТР ДП кысаларында | РМБ |
| 20. | «Чуаш сандугачы» чуаш җырын башкаручыларның республика конкурсы | апрель | Төп эшчәнлек кысаларында | «РМЙ» МБУ<br>ТР Халыклар ассамблеясенең АМР вәкиллеге |
| 21. | Бөек Җиңү көненә багышланган СССР халыклары телләрендә плакатлар һәм газеталар күргәзмәсе | май | Төп эшчәнлек кысаларында | МУ |
| 22. | Рус халык бәйрәмендә «Каравон»да катнашу | май | Төп эшчәнлек кысаларында | «РМЙ» МБУ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| 23. | «Бәрмәнчек бакчасы» керәшен православие мәдәнияте фестивале | май | Төп эшчәнлек кысаларында | «РМЙ» МБУ |
| 24. | Славян язуы һәм мәдәнияте көненә багышланган «Кириллица» балалар-яшүсмерләр хор иҗаты фестивале | май | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |
| 25. | Россия Федерациясе субъектлары мәгарифе эчтәлегенең этномәдәни (татар) компоненты булган мәгариф оешмалары җитәкчеләре һәм укытучылары өчен квалификация күтәрү курсларында катнашуны тәэмин итү | май, декабрь | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |
| 26. | А.С. Пушкинның туусына 222 ел тулуга багышланган чаралар, шул исәптән язучылар белән иҗади очрашулар, китап күргәзмәләре, семинарлар, ачык дәресләр үткәрү (мәгариф оешмаларының, мәдәният учреждениеләренең, яшьләр сәясәтенең, халыкны социаль яклау учреждениеләренең аерым планнары буенча) | 6 нчы июнь | Төп эшчәнлек кысаларында «2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | МУ, РМБ, ЯЭСБ, СЯБ |
| 27. | Россия көненә багышланган чаралар үткәрү, шул исәптән:<br>- бәйрәм концерт программалары;<br>- балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән тематик чаралар (мәгариф оешмаларының, мәдәният учреждениеләренең, яшьләр сәясәтенең аерым планы буенча) | 12 нче июнь | Төп эшчәнлек кысаларында | МУ, РМБ, ЯЭСБ, СЯБ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| 28. | «Балтай» мордва (эрзя) мәдәниятенең республика бәйрәме (аерым план буенча) | июнь | | «РМЙ» МБУ |
| 29. | «Алексеевск кыңгыраулары» халыкара фестивален оештыру һәм уздыру | июнь | | МУ |
| 30. | АМР торак пунктларында «Сабантуй» татар халык бәйрәмен уздыру | июнь | | «РМЙ» МБУ, «В.И. Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ |
| 31. | «Алексеевск муниципаль районында Татарстан халыкларының Калейдоскоп мәдәнияте» укучылары өчен муниципаль социаль-мәдәни мәгариф проекты:<br>- чуваш, удмурт, мари, мордва халыкларының матди һәм рухи мәдәниятен өйрәнү буенча күпләп яшәгән Татарстан Республикасы торак пунктларына читтән торып экспедицияләр;<br>- Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Идел буе халыкларының матди һәм рухи мәдәниятен өйрәнү буенча комплекслы экспедицияләр йомгаклары буенча түгәрәк өстәл;<br>- «Алексеевск муниципаль районында Татарстан халыкларының Калейдоскоп мәдәнияте» брошюрасын әзерләү һәм бастырып чыгару | июнь – сентябрь<br>ноябрь<br>ноябрь | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |
| 32. | Державинның шигърият фестивалендә катнашу | 14 нче июль | Төп эшчәнлек кысаларында | «АБСМ» ӨББ МБО, РМБ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| 33. | «Иван Купалы» славян мәдәнияте республика бәйрәме | июль | | «РМЙ» МБУ<br>ТР Халыклар ассамблеясенең АМР вәкиллеге |
| 34. | Чуваш мәдәниятенең «Уяв» республика бәйрәме | июль | | «РМЙ» МБУ<br>ТР Халыклар ассамблеясенең АМР вәкиллеге |
| 35. | Керәшеннәрнең «Питрау» республика мәдәният бәйрәме | июль | | «РМЙ» МБУ<br>ТР Халыклар ассамблеясенең АМР вәкиллеге |
| 36. | Татарстан Республикасында яшәүче халыклар телләрендә диктантлар һәм иншалар язу буенча иҗтимагый акцияләрдә катнашу | июль | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ, МУ, ЯЭСБ |
| 37. | «Чишмә җәннәте» муниципаль милләтара һәм конфессияара фестивален оештыру һәм уздыру | июль | Төп эшчәнлек кысаларында | «РМЙ» МБУ |
| 38. | «Сәләт» Халыкара яшьләр мәгариф форумының тематик сменаларында катнашу | Июнь-август | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ, ЯЭСБ, «АБСМ» ӨББ МБО, «РМЙ» МБУ |
| 39. | «Сәләт» Халыкара яшьләр мәгариф форумында BILER FORUM катнашу | 3-7 нче август | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |
| 40. | Россия Федерациясе Дәүләт флагы көненә багышланган чаралар, шул исәптән тематик | 22 нче август | Төп эшчәнлек кысаларында | МУ, РМБ, ЯЭСБ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | чаралар, иҗади мастер-класслар һәм конкурслар белән концерт программалары. | | | |
| 41. | Татарстан Республикасы көненә багышланган чаралар үткәрү | август | Төп эшчәнлек кысаларында | МУ, РМБ, ЯЭСБ, «Татмедиа» филиалы («Таң» газетасы («Заря») |
| 42. | Алексеевск муниципаль районында Татар мәгарифе тарихы музеен төзү | август | | РМБ |
| 43. | «Мәдәниятләр мозаикасы» Республика этноконфессиональ фестивалендә катнашу | август | «2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | «РМЙ» МБУ, РМБ, ЯЭСБ |
| 44. | «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивалендә катнашу | август | «Татар халкының милли тиндәшлеген саклап калу (2020 - 2023 еллар)» ТР ДП кысаларында | «РМЙ» МБУ ТР Халыклар ассамблеясенең АМР вәкиллеге |
| 45. | Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган «Туган киңлекләр» I Бөтенроссия пленэрендә катнашу | сентябрь – октябрь | финанслау чыганагы билгеләнмәгән | «БСМ» ӨББ МБО |
| 46. | «Безнең йорт - Татарстан» Республика этномәдәни фестивалендә катнашу | сентябрь – ноябрь | «2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында | «РМЙ» МБУ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | | | милли сәясәтне гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | |
| 47. | Славян язуы һәм мәдәнияте көненә багышланган студентлар һәм мәктәп укучылары өчен «Рус теле һәм славян дөньясы» фәнни-гамәли конференциядә катнашу | 20 нче октябрь | «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» ТР ДП кысаларында | РМБ |
| 48. | «АТАЛАН» укучыларның милли белем форумында мәктәпкәчә һәм башлангыч мәктәп яшендәге балаларны чуваш халкы мәдәниятенә җәлеп итү максатларында катнашу | октябрь | | РМБ |
| 49. | Зур Тигәнәле авылында «Мәүлид бәйрәме» үткәрү | октябрь | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ, «РМЙ» МБУ, «В.И.Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ |
| 50. | «Җәлил укулары» Халыкара китап укучылар конкурсының татар шагыйре, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилгә багышланган чаралар кысаларында муниципаль этабын оештыру һәм | октябрь-ноябрь | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ, «РМЙ» МБУ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | үткәрү | | | |
| 51. | «Балаларны туган (татар, чуаш, удмурт, мари, мордва) телендә укытуны һәм тәрбияләүне оештыру буенча иң яхшы балалар бакчасы» республика конкурсы | октябрь | финанслау чыганагы билгеләнмәгән | РМБ |
| 52. | «Россия халыкларының туган телләре: хәзерге заман мәгарифе шартларында телләр укыту актуаль мәсьәләләре» республика форумында катнашу | октябрь | финанслау чыганагы билгеләнмәгән | РМБ |
| 53. | «Рус телендә сүз әйтергә телим…» ораторлык осталыгының муниципаль конкурсы | октябрь | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ, «РМЙ» МБУ, «БСМ» ӨББ МБО |
| 54. | Халык язучылары һәм шагыйрьләре катнашында (төрле телләрдә) «Поэзия чарующие строки» Бөтенроссия фестивале | октябрь | финанслау чыганагы билгеләнмәгән | «ҮКС» МБУ, «РМЙ» МБУ, РМБ |
| 55. | Мәктәп укучылары өчен «Туган сөйләм» республика әдәби конкурсы (төрле телләрдә) | октябрь | финанслау чыганагы билгеләнмәгән | РМБ |
| 56. | «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә бәйрәме | октябрь | «2016 - 2023 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» ТР ДП кысаларында | Архивный отдел Исполнительного комитета АМР |
| 57. | Татарстан Республикасы мәгариф учреждениеләре өчен туган телләрне саклау һәм үстерү | октябрь | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | мәсьәләләре буенча республика семинарларында һәм лекцияләрендә катнашу | | | |
| 58. | Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган «Алтын битлек» театр коллективлары фестивале | октябрь-ноябрь | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ, «РМЙ» МБУ |
| 59. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары катнашында Татарстан Республикасы Конституциясе көненә багышланган чаралар үткәрү | 6 нчы ноябрь | | РМБ |
| 60. | Татарстан Республикасы Дәүләт флагы көненә багышланган чаралар, шул исәптән мәгълүмати классны сәгатьләр, танып белү семинарлары, тематик чаралар, иҗади мастер-класслар һәм конкурслар белән концерт программалары. | 29 нчы ноябрь | | МУ, РМБ, ЯЭСБ, «Татмедиа» филиалы («Таң» газетасы («Заря») |
| 61. | «Чыганакларга сәяхәт» республика конкурсы | ноябрь | Төп эшчәнлек кысаларында | ЯЭСБ |
| 62. | «Сәйяр» республика театр-конкурсы | ноябрь | «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» ТР ДП | РМБ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | | | кысаларында | |
| 63. | Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында Россия Федерациясе Конституциясе көненә багышланган чаралар, шул исәптән иҗтимагый һәм бәйрәм чаралары, лекцияләр, мәгълүмат сәгатьләре | 12 нче декабрь | Төп эшчәнлек кысаларында | МУ, РМБ, ЯЭСБ, «Татмедиа» филиалы («Таң» газетасы («Заря») |
| 64. | Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган Алексеевск муниципаль районы язучылары һәм шагыйрьләре әсәрләрен бастырып чыгару | декабрь | финанслау чыганагы билгеләнмәгән | «ҮКС» МБУ, АМР башкарма комитеты |
| 65. | Татарстан Республикасында яшәүче халыклар телләре буенча республика фән олимпиадаларында һәм милли әдәбиятларда катнашу (аерым план буенча) | декабрь | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |
| 66. | «Татарстан Республикасының рус традицион мәдәнияте» республика проектын гамәлгә ашыру | декабрь | «2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | МУ |
| 67. | Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын уздыру йомгаклары буенча методик материалны гомумиләштерүне иң яхшы тәкъдир итүгә мәгариф | Декабрь | | РМБ |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | оешмалары өчен муниципаль конкурс | | | |
| 68. | «Күпкырлы Татарстан» күчмә фотокүргәзмәсе эше | ел дәвамында | «2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | ЯЭСБ |
| 69. | Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган күргәзмәләр оештыру (мәдәният учреждениеләренең һәм мәгариф оешмаларының аерым планы буенча) | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | МУ, РМБ |
| 70. | «Мәдәният теле һәм гореф-гадәтләр - Татарстан халыклары бердәмлеге» чаралары комплексы үткәрү | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | МУ |
| 71. | Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең берләшү факторы булган тарихи даталарны популярлаштыру буенча белем алучылар өчен муниципаль социаль-мәдәни белем бирү проекты | ел дәвамында | «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» ТР ДП кысаларында | РМБ |
| 72. | Татарстан Республикасы халыкларының милли телләре көннәрен үткәрү (мәдәният һәм мәгариф оешмаларының аерым планы буенча) | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | «РМЙ» МБУ<br>ТР Халыклар ассамблеясенең АМР вәкиллеге |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| 73. | Мәдәният учреждениеләренең танылган мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре белән рәсми социаль челтәрләрендә «турыдан-туры эфирлар» үткәрү | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | МУ |
| 74. | Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган класс сәгатьләре, мәгълүмати линейкалар, укучылар һәм тәрбияләнүчеләр белән тематик кичәләр оештыру һәм үткәрү | Ел дәвамында Айга бер тапкыр | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |
| 75. | «Туган тел - милләт байлыгы» дигән тел күптөрлелегенә багышланган мәгариф оешмалары китапханәләрендә интерактив күргәзмәләр, китапханә дәресләре, уку кичәләре, тематик әңгәмәләр оештыру һәм үткәрү | Ел дәвамында Айга бер тапкыр | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |
| 76. | Иҗтимагый-мәдәни билгеләнештәге мәгариф оешмаларында (мәдәният йортлары, киноучреждение, китапханәләр, музейлар) туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган чараларга йөрүне оештыру | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | РМБ |
| 77. | Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган спортның төрле төрләре буенча спорт ярышлары, турнирлар, дусларча очрашулар уздыру | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | ЯЭСБ |
| 78. | Тематик кинокүрсәтүләр һәм кинолекторийлар (шул исәптән хәйрия) үткәрү | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | Киноучреждение |
| 79. | «Алексеевск районының географик атамаларының җирле топонимикасы» темасына тикшеренү эше | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | «В.И. Абрамов исемендәге туган як |

| Тәр-тип са-ны | Чараның исеме | Үткәрү датасы | Финанслау, мең сум | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | | | | музее» МБУ |
| 80. | Мәктәп укучылары һәм өлкән буын «Туган як топонимикасында Татарстан халыклары теле» өчен тематик музей-агарту чаралары | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | «В.И. Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ |
| 81. | Викторина (уен-шөгыль) «Слова простые, слова родные» кече мәктәп укучылары өчен | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | «В.И. Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ |
| 82. | «Матбугат сүзендә туган телнең гүзәллеге» күргәзмәсе | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | «В.И. Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ |
| 83. | «Борынгы каллиграфия» каллиграфия мастер-классы | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | «В.И. Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ |
| 84. | Кече мәктәп укучылары өчен этнография буенча кызыклы музей дәресләре «Яшәгән ди, булган ди әби белән бабай»/ «Әби янында кунакта» | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | «В.И. Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ |
| 85. | «Алексеевск ягының этнографиясе һәм көнкүреше» урта звеносы укучылары өчен лекция-экскурсия, интерактив күрсәтү | ел дәвамында | Төп эшчәнлек кысаларында | «В.И. Абрамов исемендәге туган як музее» МБУ |

* Файдаланган кыскартулар исемлеге:

МУ (мәдәният учреждениеләре): «РМЙ» МБУ (Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының район мәдәният йорты» МБУ), «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының В.И. Абрамов исемендәге

туган як музее» МБУ, «ҮКС» МБУ («Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУ), «АБСМ» ӨББ МБО(Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү МБО), Киноучреждение (Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль кино учреждениесе);

«АБСМ» ӨББ МБО - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү МБО;

ЯЭСБ - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;

РМБ - «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ;

СЯБ - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районындагы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге;

АМР – Алексеевск муниципаль районы;

«2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» ТР ДП - «2014 - 2023 елларга Татарстан Республикасында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы.

**Совет аппараты җитәкчесе** **А.С. Харитонов**